| | |
|---|---|
| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ<br>***РАЙОНЫ***<br>***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ*** | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ<br>***МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН***<br>***БУИНСКИЙ***<br>***ГОРОДСКОЙ СОВЕТ*** |

**КАРАР**

РЕШЕНИЕ

10.09.2026 №2-18

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы шәһәр Советының 2019 елның 29 мартындагы 1-41 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы (28.12.2025 редакциясендә), «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50 ТРЗномерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы (26.02.2026 ред.) нигезендә һәм муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан Буа шәһәр Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы шәһәр Советының 2019 елның 29 мартындагы 1-41 номерлы карарына ( 05.02.2020 № 5-52, 03.10.2022 № 2-22, 03.04.2024 № 1-45, 01.06.2026 № 2-14 ред ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Механизмга кушымтаның 19 бүлегенең 19.13 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

««Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 2 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның

һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларның счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы Рәисе (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә күрсәтелгән затларга карата тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка җаваплылыкның башка чарасын куллану турында гариза белән мөрәҗәгать итә.»

2. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа шәһәре башлыгы

Совет рәисе

Р.Р. Камартдинов